| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.12.2019 г. Казань № 1344 од

Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1016 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 9 июнендәге 472 од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган) расланган Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

**Министр** **И.Х.Әюпова**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1016 од номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2019 елның 18 декабрендәге 1344 од номерлы боерыгы редакциясендә) расланган

**Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә иң яхшы хезмәткәрләргә һәм учреждениеләргә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын гамәлгә кую тәртибе турында» 2008 елның 21 ноябрендәге 826 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын (алга таба – грант) ел саен бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре – Татарстан Республикасы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең мәдәният учреждениеләре: театр-тамаша, концерт оешмалары, цирклар, музейлар, музей-тыюлыклар, күргәзмә заллары һәм картина галереяләре, мәдәни-ял итү учреждениеләре, китапханәләр, мәдәният өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре, мәдәният өлкәсендә урта һөнәри белем бирү учреждениеләре, киноучреждениеләр, башка мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре;

гариза бирүче – конкурста катнашу өчен гаризаны әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә биргән мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениесе;

конкурс – мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрен грантлар бирү өчен конкурс нигезендә сайлап алу белән бәйле чара;

грант – субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

грант бирүче – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба –

Министрлык) аша мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә грантлар бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (Татарстан Республикасы Хөкүмәте);

грант алучы – конкурс җиңүчесе дип танылган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениесе;

хисап чоры – грантлар бирү елыннан соң килүче финанс елы;

агымдагы ел – конкурста катнашу өчен гариза бирелгән ел.

1.4. Грантлар берьюлы 6 грант алучыга бирелә: 2 грант һәркайсы 1 000,0 мең сум һәм 4 грант һәркайсы 500,0 мең сум күләмендә.

## 2. Грант бирү максатлары һәм шартлары

2.1. Грант бирү максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең яңа технологияләрен гамәлгә кертү һәм аларны күрсәтүнең югары сыйфатына ирешү;

иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрен ачыклау һәм кызыксындыру.

2.2. Грант түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

2.2.1. Гариза бирү датасына гариза бирүченең түбәндәге таләпләргә туры килүе:

бетерелү, банкротлыкка чыгу процессында түгел;

Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акча алучылар булып тормый;

мөрәҗәгать итүче грант алу өчен конкурста катнашуга гариза бирү датасына кадәр ике ел дәвамында шушы конкурс буенча грант алмаган һәм тәкъдим ителгән проект агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс чараларын алмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрен, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакыты чыккан бүтән бурычлары юк;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнарны, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

чит ил юридик затлары, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кергән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше устав (җыелма) капиталында барлыгы 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булып тормыйлар;

2.2.2. Гариза бирүчене грантлар бирелүгә гаризалар сайлап алу конкурсында җиңүче дип тану;

2.2.3. Гариза бирүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органның конкурс сайлап алуында катнашуга ризалыгы.

## 3. Грант алуга конкурс үткәрү тәртибе

3.1. Грантлар бирү конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.2. Грант алучыларны билгеләү өчен Министрлык, мәдәният өлкәсендә иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендәге белгечләр булып торган экспертлардан гыйбарәт, алар грант алуга дәгъва итүчеләр булмаска тиеш, иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы (алга таба – Грантлар буенча совет), составында Грантлар буенча совет рәисе һәм әгъзалары булып, 15 кешедән төзелә.

3.3. Грантлар буенча советның персональ составы, конкурсны үткәрү вакыты Министрлык боерыгы белән раслана.

3.4. Министрлык әлеге Нигезләмә кысаларында:

конкурс үткәрүне оештыра;

конкурс, конкурста катнашучыларга карата таләпләр, конкурс сроклары турында мәгълүмат бастыруны тәэмин итә;

гаризалар һәм аларга кушып бирелгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

Грантлар буенча совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

грант бирү турында Грантлар буенча совет карарын Министрлык боерыгы белән раслый;

грант алучылар белән грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи;

бирелгән грантларның максатчан тотылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

3.5. Конкурсны үткәрү турында белдерү, конкурсны үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, гаризаларны кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты, гаризаларны гавәми яклау көне турында белешмәләрне дә кертеп, конкурс үткәрү турында боерык чыккан көннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көнлек срокта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

Гаризаларны кабул итү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтына конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 14 көнлек срокта башкарыла.

3.6. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

3.6.1. Әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча грант алуга гариза, шул исәптән анда түбәндәгеләр турында мәгълүмат булырга тиеш:

гариза бирүче бетерелү, банкротлыкка чыгу процессында түгел;

гариза бирүче Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акча алучы булып тормый;

гариза бирүченең субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрен, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакыты чыккан бүтән бурычы юк;

гариза бирүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

гариза бирүче чит ил юридик заты, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кергән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше устав (җыелма) капиталында барлыгы 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормый;

3.6.2. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең яңа технологияләрен гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән проект;

3.6.3. Тәкъдим ителгән проектны гамәлгә ашыру өчен чыгымнар сметасы (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта);

3.6.4. Тәкъдим ителгән проектны гамәлгә ашыру буенча чаралар планы («юл картасы») (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта);

3.6.5. Карала торган проблематика буенча үткәрелгән социологик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре (булган очракта);

3.6.6. Теләк белдерелгән очракта, гариза бирүченең булу урыны буенча салым органына исәпкә куелу турында таныклык күчермәсе яки язылган бит, гариза бирүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлми калган бурычларының булмавын раслаучы салым органы белешмәсе (салым декларациясе коды (КНД) 1120101 формасы).

Әгәр күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган булса, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала;

3.6.7. Гариза бирүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органның бланкында рәсмиләштерелгән конкурс сайлап алуында катнашуга ризалыгы.

3.7. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар кәгазь һәм электрон чыганакларда (флеш-туплагычларда) әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктына ярашлы рәвештә Министрлык боерыгы белән билгеләнә торган срокларда турыдан-туры Министрлыкка тапшырыла.

3.8. Конкурста катнашуга кире кагу өчен нигез түбәндәгеләр була:

гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 2.2.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

тулы булмаган документлар комплектын тапшыру яки аларның әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

документларда дөрес булмаган белешмәләр булу;

гариза бирүче мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениесе түгел;

гаризалар һәм документлар гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң тапшырыла.

3.9. Конкурска төгәлләнгән (гамәлгә ашырылган) проектларга гаризалар кабул ителми.

3.10. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризалар һәм аңа кушып тапшырылган документлар рецензияләнми, кире кайтарылмый һәм Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә саклана.

3.11. Конкурс ике этапта үткәрелә:

беренчесе – эшчәнлекнең төп төре буенча күрсәткечләр нигезендә гариза бирүчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә эксперт бәяләве алу;

икенчесе – мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүнең яңа технологияләрен гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән проектны Грантлар буенча совет утырышында тәкъдим итү һәм гавәми яклау. Һәр чыгышка өч минутка кадәр вакыт бирелә.

3.12. Гариза бирүчеләргә проектларны гавәми яклау вакыты, урыны турында, әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән проектны гавәми яклау датасына кадәр 7 (җиде) эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.13. Гаризаларны бәяләү Грантлар буенча совет тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

| № т/б | Гаризаларны бәяләү критерийлары | Бәяләү (баллар) |
|---|---|---|
| 1. Гариза бирүчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү буенча конкурсның беренче этабы критерийлары | | |
| 1.1. | Агымдагы елда, шулай ук гариза бирү елына кадәрге ике ел эчендә дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәү | Үтәлмәү – 0;<br>тотрыклы үтәп бару – 1 |
| 1.2. | Агымдагы елда федераль һәм региональ массакүләм мәгълүмат чараларында учреждениенең һәм хезмәткәрләрнең эшчәнлеге яктыртылу | ММЧда мәгълүмат бирелми – 0;<br>федераль һәм региональ дәрәҗәдә учреждениенең эшчәнлеге турында уңай бәяләмә белән басма материал (телетапшыру) бар – 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 1.3. | Гариза бирү датасына хезмәткәрләрнең гомуми санына карата дәүләт бүләкләре (орденнар, медальләр, мактаулы исемнәр) булган хезмәткәрләре санының процентларда чагыштырмасы | Бүләкләнүчеләр юк – 0;<br>10% кадәр – 1;<br>10 % һәм аннан күбрәк – 2 |
| 1.4. | Гариза бирүченең соңгы ике елдагы (агымдагы ел һәм гариза бирү елына кадәрге ел) зур казанышлары һәм мәдәният үсешенә керткән өлеше | Казанышлар юк – 0;<br>статистик күрсәткечләр белән раслана торган казанышлар бар, уңай бәяләмәләр алган программалар һәм проектлар тормышка ашырылган – 8;<br>эшнең яңа формалары тәкъдим ителгән, эшләнгән, гамәлгә кертелгән; республика әһәмиятендәге чаралар гамәлгә ашырылган; тиражлау өчен уңай тәҗрибә бар; хезмәткәрләрнең шәхси казанышлары бар – 10 |
| 2. | Проектларны бәяләү буенча конкурсның икенче этабы критерийлары | |
| 2.1. | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | Проект туры килми – 0;<br>проект туры килә – 5 |
| 2.2. | Проектның яңалыгы, тәкъдим ителә торган карарларның, технологияләрнең һәм алымнарның инновациялелеге | Проект танылган продуктны тәкъдим итә һәм ул инновация булып тормый – 0;<br>проект шактый үзгәртелгән, билгеле алымнар, технологияләр, программалар камилләштерелгән продукт тәкъдим итә (яңалык) – 3;<br>проект принципиаль яңа продукт тәкъдим итә (инновация) – 5 |
| 2.3. | Проектны тормышка ашыру өчен планлаштырыла торган чыгымнарның нигезләнгән булуы | Планлаштырыла торган чыгымнар куелган максатка ирешүгә һәм проект бурычларын хәл итүгә туры килми – 0;<br>планлаштырыла торган чыгымнар проектның куелган максатына ирешүгә һәм бурычларын хәл итүгә тулысынча туры килеп бетми – 3;<br>планлаштырыла торган чыгымнар чынбарлыкка туры килә, проектның бурычларын хәл итүгә һәм максатларына ирешүгә туры килә, ресурсларның тасвирламасына нигезләнә һәм план белән туры килә – 5 |
| 2.4. | Проектны бюджеттан тыш | Финанслашу юк – 0; |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм башка чыганаклар чаралары хисабына финанслашуның фаразлана торган өлеше | кимендә 10% – 2;<br>10 алып 20% ка кадәр – 3;<br>20% тан күбрәк – 5 |
| 2.5. | Проект чараларының проектны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләренә туры килүе, мондый нәтиҗәләрне исәпләп чыгара алу һәм мондый нәтиҗәләргә ирешү | Проект бу критерийга туры килми – 0;<br>чаралар планы проектның куелган максатына ирешүнең һәм бурычларын хәл итүнең барлык аспектларын җитәрлек дәрәҗәдә чагылдырмый – 3;<br>чаралар планы тәгәллеге белән аерылып тора, проект бурычларын хәл итәргә ярдәм итә – 5 |
| 2.6. | Проектны тормышка ашыруга социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү | Җәлеп итү планлаштырылмый – 0;<br>кимендә өчне җәлеп итү планлаштырыла – 3;<br>өчтән артык оешманы һәм (яки) физик затларны җәлеп итү планлаштырыла – 5 |
| 2.7. | Проектны тормышка ашыру масштабы | Проект күрсәтелгән территорияләр белән үзара хезмәттәшлек итүне күздә тотмый яисә алар белән хезмәттәшлек итү исбатланмаган – 0;<br>территория чикләрендәге эшчәнлек партнерлар җәлеп итү хисабына булыр дип күздә тотыла, әмма алар белән тотрыклы элемтәләрнең булуы расланмаган – 3;<br>проект партнерлары актив җәлеп ителеп, күрсәтелгән территориаль колачлау дәлилләнгән – 5 |
| 2.8. | Грант буенча финанслау тәгәлләнгәннән соң проектны алга таба үстерү перспективасы булу | Проектны алга таба үстерү перспективасы дәлилләнмәгән – 0;<br>проектны алга таба үстерү перспективасын дәлилләү тиешле дәрәҗәдә ышандырмый – 3;<br>проектны алга таба үстерү перспективасы төгәл план һәм социаль партнерларның кызыксынуы белән расланган – 5 |
| 2.9. | Проектка ихтыяҗ булу һәм тәкъдим ителгән проектны массакүләм практикада куллану (тиражлау) мөмкинлеге булу | Проектны тиражлау мөмкинлеге дәлилләнмәгән – 0;<br>проектны тиражлау мөмкинлеген дәлилләү тиешле дәрәҗәдә ышандырмый – 3;<br>проектны тиражлау мөмкинлеге мисаллар белән дәлилләнгән – 5 |

3.14. Грантлар буенча совет әгъзасы һәр критерий буенча баллар бирә, һәм алар кушыла.

3.15. Баллар эксперт битләренә куела, Грантлар буенча совет әгъзасы имзасы белән раслана һәм Грантлар буенча совет рәисенә тапшырыла.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.13 пунктында күрсәтелгән критерийларларга нигезләнеп Грантлар буенча совет әгъзалары тарафыннан куелган балларны кушу нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең йомгаклау рейтингы җыелган баллар кими бару тәртибендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең түбәндәге ике төркеме буенча төзелә:

1 төркемдәге гариза бирүчеләр – 1 000,0 мең сумга гаризалар биргән мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре;

2 төркемдәге гариза бирүчеләр – 500,0 мең сумга гаризалар биргән мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре.

3.17. Бер үк санда балл җыйган гариза бирүчеләр рейтингта гариза бирү датасы буенча тәртипкә салына.

3.18. Грантлар буенча совет гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көнлек срокта әлеге Нигезләмәнең 3.16 пунктында каралган рейтинглар нигезендә, грант алучылар исемлеген билгели.

3.19. 1 000,0 мең сум күләмендә грант алуга конкурсның җиңүчеләре дип конкурсның икенче этабы нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең беренче төркеме рейтингында 1 һәм 2 урыннарны алган гариза бирүчеләр танылa.

3.20. 500,0 мең сум күләмендә грант алуга конкурсның җиңүчеләре дип конкурсның икенче этабы нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең икенче төркеме рейтингында 1 һәм 4 урыннарны алган гариза бирүчеләр танылa.

3.21. Утырыш, әгәр анда Грантлар буенча совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

3.22. Грантлар буенча совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

3.23. Грантлар бирү турында боерык чыккан көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтына грант алучылар турында мәгълүмат урнаштырыла.

3.24. грант алучылар турында боерык чыккан көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көнлек срок эчендә Министрлык һәм грант алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча килешү төзелә.

3.25. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант күләме;

грант бирү максатлары;

грант күчерү тәртибе һәм сроклары;

грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

гранттан файдалану турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы;

грант күчерүне туктатып тору, туктату нигезләре һәм грант күләмен киметү һәм кире кайтару тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрү сроклары;

грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне тикшерүне Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга грант алучының ризалыгы;

килешү шартларын бозган өчен җаваплылык.

## 4. Грант алучыларга акча түләү тәртибе

4.1. Грант алучыларга акча Министрлык тарафыннан, Министрлык һәм грант алучы арасындагы килешүгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль органында ачылган шәхси счетларга субсидияләр рәвешендә күчерелә.

## 5. Грант алучылар тарафыннан хисап бирү тәртибе һәм сроклары

5.1. Грант алучылар Министрлыкка грант түләүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалану турында һәм проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре хакында хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр срокта хисаплар тапшыралар.

5.2. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисапта түбәндәге позицияләрне күрсәтергә киңәш ителә:

куелган максатларга һәм бурычларга ирешү;

грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең килешүдә билгеләнгән зурлыгына, гаризада күрсәтелгән сыйфат һәм сан нәтиҗәләренә ирешү;

проектны алга таба гамәлгә ашыру һәм аны тиражлау мөмкинлеге;

учреждениенең проектны гамәлгә ашыру буенча иҗади эшчәнлеге турында җәмәгатьчелек фикеренә (массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләренә) күзәтү;

проектны гамәлгә ашыру буенча фотоматериаллар.

5.3. Грант түләүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану турындагы хисап әлеге Нигезләмәнең 3.24 пунктында каралган килешү нигезендә ике нөсхәдә язма рәвештә тапшырыла.

5.4. Хисапка беренчел финанс документлары күчермәләре теркәлә.

5.5. Хисап елыннан соң килә торган финанс елының беренче гыйнварына кулланылмыйча калган грант акчалары, килешүдә билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның тиешле таләбе алынганнан соң, 15 эш көне эчендә грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

5.6. Грантны максатка ярашсыз файдалану факты ачыклану турында Министрлык грант алучыга грант алучының гранттан максатка ярашсыз файдалануы факты ачыклаган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта хәбәр итә.

5.7. Грант алучы Министрлыкның тиешле таләбе алынганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек срокта грантны түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиеш:

грант алу өчен грант алучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу;

әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә билгеләнгән грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең грант алучы тарафыннан үтәлмәве;

нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү;

грант алучының гранттан максатчан файдаланмавы.

Грант алучы тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән нигезләр буенча грантны кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык әлеге пунктта билгеләнгән срок чыкканнан соң 7 эш көне эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтару буенча чаралар күрә.

5.8. Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ихтыярый кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

5.9. Грант алучылар тарафыннан грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри тикшерүләр үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы гамәлгә ашыра.

Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Форма

**Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын алуга гариза**

Оешманың тулы исеме (устав нигезендә) ___________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
Адрес (индексы белән)_______________________________________________
Оешма җитәкчесе____________________________________________________
Әлеге вазыйфада эш стажы ____________________________________________
Элемтә өчен телефон _________________________________________________

| | |
|---|---|
| **Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре** | |
| Эшчәнлек төре буенча кыскача аналитик белешмә, ул агымдагы елда дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмәсенең үтәлеше турында белешмәләрне, шулай ук гариза бирү елына кадәрге ике ел эчендә, шул исәптән күрсәткечләрнең чагыштырма характеристикасын (теркәлгән кулланучылар саны – китапханәләр өчен, төрле дәрәҗәдәге иҗади конкурсларда җиңгән укучылар саны – мәдәният өлкәсендә белем бирү учреждениеләре өчен; клуб формированиеләрендә катнашучы халыкның чагыштырма нисбәте – мәдәни-ял итү учреждениеләре өчен; килүчеләр (тамашачылар) саны – башка мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре өчен) үз эченә ала: | |
| 20___ елда (агымдагы елда) | *Гаризалар кабул ителә башлаган датага* |
| 20__ елда (заявка бирү елына кадәрге елда) | *Еллык федераль статистика хисабы формасыннан* |
| 20___ елда (гариза бирү елына кадәрге 2 елда)<br>(мисал буларак, 2019, 2018, 2017) | *Еллык федераль статистика хисабы формасыннан* |
| Агымдагы елда федераль һәм региональ массакүләм мәгълүмат чараларында учреждениенең һәм хезмәткәрләрнең эшчәнлеге яктыртылу | |
| федераль ММЧ | *Учреждение эшчәнлеге турында уңай бәяләмәләр саны, вакыйганың исеме, ММЧ* |

| | |
|---|---|
| | *күрсәтелә* |
| региональ ММЧ | *Учреждение эшчәнлеге турында уңай бәяләмәләр саны, вакыйганың исеме, ММЧ күрсәтелә* |
| Гариза бирү датасына хезмәткәрләрнең гомуми санына карата дәүләт бүләкләре (орденнар, медальләр, мактаулы исемнәр) белән бүләкләнгән булган хезмәткәрләр санының процентларда чагыштырмасы | |
| Хезмәткәрләрнең гомуми саны, кеше. | *Хезмәткәрләрнең гомуми саны күрсәтелә (белгечләр, хезмәт күрсәтүче һәм тәэмин итүче персонал)* |
| Дәүләт бүләкләре (орденнары, медальләре, мактаулы исемнәре) булган хезмәткәрләр саны | *Дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләрнең гомуми саны күрсәтелә (бер хезмәткәрнең ике бүләге булса, 1 тапкыр гына исәпкә алына)* |
| Учреждениенең соңгы ике елдагы (агымдагы ел һәм гариза бирү елына кадәрге ел) зур казанышлары һәм мәдәният үсешенә керткән өлеше | |
| **Проект турында кыскача мәгълүмат** | |
| Проектның исеме | |
| Проектның кыскача эчтәлеге | *Проектның төп идеясен чагылдырган проект тексты презентациясе (1000нән артык булмаган символ)* |
| Проектның актуальлеген һәм социаль әһәмиятен нигезләү | *Монда проектны булдыруга этәргән вәзгыятьне тасвирлау тәкъдим ителә. Карала торган проблематика буенча социологик тикшеренүләр булу. Проектта хәл ителергә тиеш проблеманың тасвирламасы (иң күбе 1000 символ)* |
| Проектның максаты һәм бурычлары | *Максатлар гомуми терминнар белән языла, шул ук вакытта бурычлар эшчәнлекнең төгәл бер нәтиҗәләрен билгели (нәрсәгә ирешү, нәрсәне алу планлаштырыла).* |
| Көтелгән нәтиҗәләр | |
| Сан ягыннан нәтиҗәләр | *Санлы күрсәткечләр белән исәпләнә торган төгәл нәтиҗәләр һәм проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырылган күрсәткечләрнең план буенча күрсәткечләре билгеләнә.* |
| Сыйфат нәтиҗәләре | *Проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырылган санлы күрсәткечләрдә исәпләнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә* |

| | |
|---|---|
| Проектны бюджеттан тыш чыганаклар, Россия Федерациясе бюджеты яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчалары исәбеннән финанслашу | *Финанслау чыганагын һәм сумманы (булган очракта) күрсәтергә* |
| Проектны гамәлгә ашыру сроклары | |
| Проектны гамәлгә ашыра башлау датасы | *(ай, ел)* |
| Проектны гамәлгә ашыру тәгәлләнү датасы | *(ай, ел)* |
| Партнерларның ниятләрен раслый торган документлар, шул исәптән проектны бергәләп гамәлгә ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү | *Проектны гамәлгә ашыруга мәгълүмати, консультация, оештыру, матди һәм (яки) башка ярдәм күрсәтергә әзер булган 10 партнерга кадәр (оешмалар һәм (яки) физик затлар) исемлек күрсәтелә.*<br>*Исемлек гаризага гариза бирүче теләге буенча беркетелә (проектны гамәлдә ашыруда төп партнерларның (югарыда санап кителгәннәрдән) роле һәм төгәл катнашу формалары турында мәгълүматны үз эченә алган 5 документтан да күп түгел).* |
| Проектны гамәлгә ашыру масштабы (проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территория (торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр, исемнәрен күрсәтергә) | *Торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр исемлеге күрсәтелә* |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

оешма бетерелү, банкротлыкка чыгу процессында түгел;

оешма Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1016 номерлы боерыгы белән расланган Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

оешманың субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрен, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакыты чыккан бүтән бурычы юк;

оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

оешма чит ил юридик заты, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кергән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше устав (җыелма) капиталында барлыгы 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормый.

***Учреждение җитәкчесе*** ____________________ ______________________

(имза) (ф.и.а.и.)

МУ

Дата

Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

РАСЛЫЙМ

___________________

(учреждение җитәкчесе: вазыйфасы, Ф.И.А.и.)

«____» __________, 20__ ел

М.У.

______________________________________________________________

проектны гамәлгә ашыру чыгымнары сметасы

сум

| Статьяның исеме | Грант акчалары | Башка финанслау чыганаклары акчалары | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| **Хезмәт өчен түләү*** | | | |
| Штаттагы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү | – | | |
| Штаттагы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүне хисаплау | – | | |
| Күрсәтелә торган хезмәтләр өчен штаттан тыш хезмәткәрләрнең (экспертлар, консультантлар һ. б.) хезмәте өчен түләү | – | | |
| Штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүне хисаплау | – | | |
| **Хезмәт өчен түләү буенча барлыгы** | – | | |
| **Турыдан-туры чыгымнар** | | | |
| | | | |
| | | | |
| **Турыдан-туры чыгымнар буенча барлыгы** | | | |
| **Проект буенча башка чыгымнар** | | | |
| | | | |
| | | | |
| **Барлык башка чыгымнар** | | | |

______________

* Хезмәт өчен түләү проектта каралмаган булырга мөмкин.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Проект буенча барлык чыгымнар** | | | |

Баш хисапчы (хисапчы) ______________________ И.А.и. Фамилия

(имза)

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына түбәндәге чыгымнар финансланмый:

- учреждениенең көндәлек чыгымнары: хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (шул исәптән - җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү), бинаны арендалау, шулай ук гамәлгә ашырылган яки агымдагы проект буенча чыгымнар;
- коммерциягә караган проектлар;
- проектны тормышка ашыру өчен кирәк булмаган җиһазларны сатып алу;
- бинага ремонт эшләре үткәрү.

Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Проектны тормышка ашыру буенча чаралар планы («юл картасы»)**

| № т/б | Проектның бурычы исеме | Проектны гамәлгә ашыру буенча чаралар исемлеге | Гамәлгә ашыру вакыты | Көтелгән нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат күрсәткечләрен күрсәтеп) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |